МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.02.2016 г.Казань № 14/2-пр.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен кабул итү мөмкинлеге күздә тотылган Россия Федерациясе законнары нормаларын гамәлгә куюны тәэмин итү максатларында, “Россия Федерациясе аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 10 октябрендәге 506 номерлы Указының 4 пункты нигезендә һәм “Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы Указының 3 пункты нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен кабул итүе тәртибе турында кушымтада бирелүче нигезләмәне (алга таба –

Нигезләмә) расларга.

2. Кадрлар бүлеге башлыгы А.З. Кашаповка Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
2016 елның 15 февралендәге
14/2-пр номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен кабул итүе тәртибе турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – Министрлык, граждан хезмәткәре) чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен (фән өлкәсендәгеләреннән тыш) (алга таба – мактаулы исемнәр, бүләкләр), әгәр граждан хезмәткәренең вазыйфаларына күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү керсә, кабул итү тәртибе билгеләнә.

2. Граждан хезмәткәре мактаулы исемнәр, бүләкләр алганда Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының (алга таба – министр) рөхсәтен алырга тиеш.

3. Мактаулы исем, бүләк алган яисә мактаулы исемне, бүләкне алачагы турында чит дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, бүтән иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәдән хәбәрнамә алган граждан хезмәткәре өч эш көне дәвамында Министрлыкның кадрлар бүлегенә (алга таба – кадрлар бүлеге), чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы исемен яки махсус дәрәҗәсен, бүләген кабул итеп алырга рөхсәт бирүен сорап, әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтадагы форма буенча тутырылган үтенеч язуы (алга таба – үтенеч язуы) тапшыра.

Үтенеч язуын карау вакыты, әлеге Нигезләмәнең 8 пункты нигезендә кадрлар бүлеге тарафыннан үтенеч язуын теркәү көненнән алып, ун эш көне тәшкил итә.

4. Мактаулы исемнән, бүләктән баш тарткан граждан хезмәткәре өч эш көне дәвамында кадрлар бүлегенә чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы исемен яки махсус дәрәҗәсен, бүләген кабул итеп алудан баш тартуы турында әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы форма буенча тутырылган хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) тапшыра.

5. Министр тарафыннан үтенеч язуын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгәнче мактаулы исем, бүләк алган граждан хезмәткәре мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен аларны кабул итеп алган көннән соң өч эш көне дәвамында аларны саклау өчен җаваплылык йөкләтелгән кадрлар бүлегенә тапшыра. Бу вакытта әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтадагы форма буенча тапшыру-кабул итү акты төзелә.

6. Әгәр хезмәт командировкасы вакытында граждан хезмәткәре мактаулы исем, бүләк алса яисә алардан баш тартса, үтенеч язуы яисә хәбәрнамә тапшыру вакыты граждан хезмәткәренең хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән алып санала.

7. Граждан хезмәткәре үтенеч язуын яисә хәбәрнамәне, мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен аннан тормый торган сәбәп аркасында әлеге Нигезләмәнең 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмый икән, ул үтенеч язуын яисә хәбәрнамәне, мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен мондый сәбәп бетерелгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) теркәү ул кергән көнне кадрлар бүлеге тарафыннан әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтадагы форма буенча төзелгән теркәү журналында башкарыла. Теркәлгән үтенеч язуын (хәбәрнамәне) кадрлар бүлеге ике эш көне дәвамында министрга карауга җибәрә.

9. Кадрлар бүлеге ике эш көне дәвамында үтенеч язуын карау нәтиҗәләре буенча министр карары турында граждан хезмәткәренә хәбәр итә һәм аңа, имза куйдырып, кадрлар бүлеге печате белән расланган, министр резолюциясе куелган үтенеч язуының (хәбәрнамәнең) күчермәсен тапшыра. Министр резолюциясе куелган үтенеч язуының (хәбәрнамәнең) төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшнамәсенә теркәлә.

10. Министр граждан хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенеч язуын канәгатьләндергән очракта, кадрлар бүлеге 10 эш көне дәвамында граждан хезмәткәренә мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен тапшыра. Бу вакытта әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтадагы форма буенча тапшыру-кабул итү акты төзелә.

11. Министр граждан хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенеч язуын канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, кадрлар бүлеге 10 эш көне дәвамында мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аның документларының төп нөсхәләрен чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең тиешле органына җибәрә.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәгә

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрына

___________________________________________

(Ф.И.А.и.)

___________________________________________

(вазыйфа исеме)

___________________________________________

___________________________________________

(Ф.И.А.и., телефон номеры)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең бүләген, мактаулы исемен яисә махсус дәрәҗәсен кабул итеп алырга рөхсәт турында
үтенеч язуы

___________________________________________________________________________

(бүләкнең, мактаулы исемнең яисә махсус дәрәҗәнең атамасы)

___________________________________________________________________________

(нинди казанышлар өчен кем тарафыннан бирелгән, нинди казанышлар өчен кем тарафыннан бүләкләнгән)

___________________________________________________________________________

(бүләккә, мактаулы исемгә яисә махсус дәрәҗәгә документлар тапшыру вакыты һәм урыны)

___________________________________________________________________________

кабул итеп алырга рөхсәт итүегезне үтенәм.
Мактаулы исемнең яисә махсус дәрәҗәнең документлары, бүләк һәм аңа документлар (тиешлесенең астына сызарга) ___________________________________

___________________________________________________________________________

(бүләкнең, мактаулы исемнең яисә махсус дәрәҗәнең атамасы)

___________________________________________________________________________

(бүләкнең, мактаулы исемнең яисә махсус дәрәҗәнең документлары атамасы)

___________________________________________________________________________

_____номерлы тапшыру-кабул итү акты буенча 20__ елның “___”___________Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының кадрлар бүлегенә тапшырылды.

20__ елның “___”___________ ___________ ______________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәгә

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрына

________________________________________
(Ф.И.А.и.)

________________________________________
(вазыйфа исеме)

________________________________________

________________________________________
(Ф.И.А.и., телефон номеры)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең бүләген, мактаулы исемен яисә махсус дәрәҗәсен кабул итеп алудан баш тарту турында

хәбәрнамә

______________________________________________________________________
(бүләкнең, мактаулы исемнең яисә махсус дәрәҗәнең атамасы)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(нинди казанышлар өчен кем тарафыннан бирелгән, нинди казанышлар өчен кем тарафыннан бүләкләнгән)

__________________________ кабул итеп алудан баш тартырга карар кылуым турында хәбәр итәм.

20__ елның “___”___________ ___________ ______________________
(имза) (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен кабул итүе тәртибе турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Тапшыру-кабул итү
акты

20__ елның “___”___________ №_______

Без, түбәндә имза куючылар, ______________________________________________
_____________________________________________________________________
(хезмәткәрнең Ф.И.А.и., вазыйфасы)
түбәндәгене тапшыруы/кабул итеп алуы (тиешлесенең астына сызарга),
ә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы кадрлар бүлегенең җаваплы заты __________________________________
(хезмәткәрнең Ф.И.А.и., вазыйфасы)
түбәндәгене кабул итеп алуы/тапшыруы (тиешлесенең астына сызарга) турында акт төзедек:

| т/б | Исеме | Саны (данәдә) | Тасвирлама |
|---|---|---|---|
| . | | | |
| . | | | |

Тапшырды Кабул итеп алды

___________ __________________________ ___________ __________________________
(имза) (имзаны шәрехләү) (имза) (имзаны шәрехләү)